**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 16 декабрендәге 4477 номерлы карары**

**2025-2027 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә иреклеләр (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеген раслау турында**

«2018-2025 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасы, 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы «Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында»гы федераль законның 17.4 статьясындагы 2 пункты нигезендә һәм 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы «Иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы законының 4 статьясын үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. 2025-2027 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә иреклеләр (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Чараларны үткәрү белән бәйле чыгымнарны бюджет акчаларын тиешле төп бүлүчеләрнең бюджет исемлекләрендә каралган акчалар, җәлеп ителгән иганәчелек акчалары һәм бюджеттан тыш башка чыганаклар хисабына гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 16 декабрендәге
4477 номерлы карары белән
расланды

**2025-2027 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә**
**иреклеләр (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеге**

| № т/б | Ярдәм чарасы | Ярдәм чарасы өчен җаваплы |
|---|---|---|
| 1. Оештыру буенча ярдәм | | |
| 1.1 | Казан шәһәренең иреклеләр (волонтерлык) берләшмәсе тарафыннан чаралар (форумнар, слетлар, семинарлар) үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе |
| 1.2 | Иреклеләрнең (волонтерларның) танылган шәхесләр, мәдәният, спорт һәм сәясәт эшлеклеләре, җәмәгать эшлеклеләре белән тематик очрашуларын оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты |
| 1.3 | Иреклеләрне (волонтерларны) укытуны оештыру буенча ярдәм күрсәтү (лекцияләр, семинарлар, уку-укыту буенча оештыру җыелышлары һ.б.) | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |

| № т/б | Ярдәм чарасы | Ярдәм чарасы өчен җаваплы |
|---|---|---|
| 1.4 | Иреклеләрнең (волонтерларның) шәхси кенәгәләрен рәсмиләштерүдә һәм аларны гариза буенча бирүдә ярдәм күрсәтү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 1.5 | Эшкә урнашу яки Казан шәһәренең уку йортларына укырга керү һәм төрле конкурсларда катнашу максатыннан иреклеләргә (волонтерларга) рекомендация хатлары/характеристикалар тутыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 1.6 | Иреклеләргә (волонтерларга), иреклеләр (волонтерлык) оешмаларына социаль өлкә учреждениеләренә бушлай йөрү хокукы бирү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты |
| 1.7 | «Ел иреклесе» шәһәр премиясен оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 1.8 | Иреклеләр (волонтерлык) хәрәкәте вәкилләренең, шул исәптән «көмеш» волонтерларның (55 яшьтән өлкәнрәк гражданнарның), форумнарда, слетларда, семинарларда, конференцияләрдә, мастер-классларда катнашуына булышлык итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе |
| 1.9 | Иреклеләрне (волонтерларны) «Казан волонтеры» мактау билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе |

| №<br>т/б | **Ярдәм чарасы** | **Ярдәм чарасы өчен җаваплы** |
|---|---|---|
| 2. Мәгълүмати ярдәм | | |
| 2.1 | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми ресурсларында тармак компетенциясе буенча ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендәге чаралар турында мәгълүмат урнаштыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 2.2 | Массакүләм мәгълүмат чараларын ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген яктыртуга җәлеп итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты, Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе, «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе |
| 2.3 | Ирекләләр (волонтерлык) өлкәсендә «Игелекле Татарстан» республика премиясе җиңүчеләренең эшчәнлеген мәгълүмати яктан яктырту | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 2.4 | Казанның ирекләләр үзәге ирекләләре (волонтерлары) эшчәнлеге турында видеороликлар төшерүдә ярдәм күрсәтү, ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлегенең иң яхшы практикалары тупланган җыентыклар чыгару | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |

| №<br>т/б | **Ярдәм чарасы** | **Ярдәм чарасы өчен җаваплы** |
|---|---|---|
| 2.5 | Рәсми мәгълүмат ресурсларында ирекләләр (волонтерлык) хәрәкәтенең агымдагы проектлары, чаралары, программалары, акцияләре, иң яхшы практикалары турында, социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы активистлар, төрле дәрәҗәдәге конкурсларында җиңү яулаган ирекләләр (волонтерлык) берләшмәләре турында мәгълүмат урнаштыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе, «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе |
| | 3. Консультация ярдәме | |
| 3.1 | Ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыру, конкурсларда катнашу, конкурсларда катнашу өчен документлар әзерләү, Казан шәһәренең белем бирү учреждениесе базасында ирекләләр (волонтерлык) ячейкасы оештыру мәсьәләләре буенча консультация | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе |
| | 4. Методик ярдәм | |
| 4.1 | Ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендә социаль нормалар, нормативлар һәм стандартлар эшләү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе |

| №<br>т/б | **Ярдәм чарасы** | **Ярдәм чарасы өчен җаваплы** |
|---|---|---|
| 4.2 | Казан шәһәре яшьләрен иреклеләр (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итү темасына социологик тикшеренүләр эшләү һәм үткәрү, аналитик материаллар әзерләү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе |